## КАРАР

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Карабаян торак пунктының гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 7 декабре Карабаян авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Карабаян торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Карабаян торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 1000 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Карабаян торак пунктында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

**1) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

урам утларын карап тоту, урам яктырткычларының энергия саклаучы лампаларын, яктырткычларны, махсус җайланмаларны сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

**2) Юлларны карап тоту:**

- юлларны кардан чистарту;
- Советская, Лермонтов урамнарындагы юлларга вак таш җәю, чокырларны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча түләү)?»

| « РИЗА» | «КАРШЫ» |
|---|---|

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 17 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашкан 10 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Карабаян торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлегенең Карабаян торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 1000 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Карабаян торак пунктында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

**1) Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

-урам утларын карап тоту, урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

**2) Юлларны карап тоту:**

- юлларны кардан чистарту;
- Карабаян торак пунктындагы Совет, Лермонтов урамнарындагы юлларга вак таш җәю (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча түләү), юлларны ремонтлау-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Олы Нырсы авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Нырсы авыл җирлеге Башлыгы: Р. Г. Гыйниев